ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.03.2019 с.Старое Дрожжаное № 156

2017-2020 елларга “Уңайлы тирәлек” Муниципаль программасына үзгәрешләр кертү хакында

Инвалидлар һәм халыкның мобильлеге аз булган башка төркемнәре өчен уңайлы һәм комфортлы яшәү тирәлеге булдыру максатында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 27.12.2016 ел № 798 карары белән расланган 2017-2020 елларга “Уңайлы тирәлек” Муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**программа Паспортында:**

**“Программаның бурычлары”** рәтен түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

“Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә инвалид һәм мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналарга ярдәм күрсәтүнең яңа технологияләрен һәм методикаларын кулланылуны тәэмин итү.

Инвалид һәм мөмкинлекләре чикләнгән балаларны спорт чараларына тарту, инвалид балаларның психик һәм физик сәламәтлеген яхшырту, гаиләнең психологик сәламәтлеге дәрәҗәсен арттыру өчен шартлар тудыру.

“Үзенчәлекле” балаларга карата толерант мөнәсәбәтләрне үстерү өчен инвалид балаларны сәламәт яшьтәшләре арасында күбрәк булдыру.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә инвалид һәм мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналарга ярдәм күрсәтүнең социаль тәҗрибәсе эффектив нәтиҗәләрен гомумиләштерү һәм киң кулланылышка кертү»;

**“Программаны финанслауның күләме һәм чыганаклары”** рәтен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Программаны финанслау чыганаклары:

җирле бюджет акчалары;

“Мәрхәмәтле ишегалды” проекты чараларын гамәлгә ашыруга килгән акчаларны да исәпкә алып, гомуми суммасы 2 655 мең сум булган бюджеттан тыш акчалар”;

**“Программадан көтелгән нәтиҗәләр”** рәтен түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

“- инвалид балаларны һәм инвалид бала булган гаиләләрне оешкан ял, мәдәни-ял чараларына тартуның уңай динамикасы. Инвалид балаларның сәламәт яшьтәшләре арасына социаль рәвештә якынаюы;

- инвалид балаларның физик һәм психик сәламәтлеге, аларның физкультура һәм спортка тартылу мөмкинлеге үсеше, инвалид балалар гына түгел, ә аларның гаиләләренең дә реабилитацияләнүе һәм социальләшүе, аларның социаль адаптациясе ныгу;

- авыру балаларның башкалар белән аралашу мөмкинлегенең артуы, аларга карата булган аерым игътибар һәм җәлләү спектрының читкә юнәлтелүе;

- инвалид һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар тәрбияләүче ата-аналарның позитив кәефтә булуына ирешү.

- инвалид балалар һәм аларның ата-аналарының технологик реабилитациясе үсеше”.

“2017-2020 елларга “Уңайлы тирәлек” программасы чаралары исемлеге” дип аталган **1 номерлы кушымтаны** түбәндәге эчтәлектәге 5.3. пункты белән тулыландырырга:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5.3. | “Мәрхәмәтле ишегалды” инновацион социаль проектын гамәлгә ашыру | 2019-2020 еллар | Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф, Мәдәният, Яшьләр белән эшләү, спорт һәм туризм бүлекләре; ГАУЗ «Чүпрәле Үзәк район больницасы»; Иске Чүпрәле авыл җирлеге Башкарма комитеты, МБО ДО «ДЮСШ», ГБУ ЦСОН «Кайгырту» | агымдагы финанслау |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырырга.

3. Әлеге карар бастырылып чыгарылган көннән үз көченә ия.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф.Җәлаловка йөкләргә.

Башкарма комитеты Җитәкчесе
вазифаларын башкаручы: И.Р. Измайлов